ЯЛ ИТӘРГӘ – АВЫЛГА
Азат Борһанов Салавычта агротуризмны үстермәкче
> 2

ЯЗГЫ ЯРМИНКӘ
«ВТ» хәбәрчесе дә шимбә иртәсен авыл мохитендә уздырды
> 2

СОҢГЫ ОМТЫЛЫШ
«Барыгыз да шаккатачаксыз!» – дигән иде Эдуард Хәйруллин. Өлгермәде...
> 3

ТЫЕЛМАГАН НӘФЕС
Ифтар узды, юшкыны калды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 55 (29022) | Сишәмбе | 18 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

БАЛА ХАКЫ

Пособиедән – пособиегә

Майда бакча эшләре белән акча турында онытып җибәрмәгез. Билгеле булганча, узган елның язында илдә 8дән алып 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүче гаиләләргә яңа төр пособие гамәлгә керде. Әлеге акча бер елга билгеләнгән иде һәм ул озайтылмаячак, дип кисәтә белгечләр.

Шуңа күрә бу пособиене алга таба да алырга теләүче әти-әниләргә кабат гариза язарга кирәк. Быел балалар өчен түләүләргә бәйле үзгәрешләр дә бар. Акча кемгә һәм күпме тиеш?

8дән алып 17 яшькә кадәр балаларга айлык акча Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча узган елның 1 маеннан гамәлгә керде. Дөрес, әлеге акчага аз керемле гаиләләр генә дәгъва кыла ала. 8дән 17 яшькә кадәр балаларга пособие рәсмиләштерү өчен, гаиләнең айлык кереме, пенсия, стипендия һәм башка төр түләүләрне дә кертеп, җан башына төбәктәге яшәү минимумыннан артмаска тиеш. Быелның 1 гыйнварына Татарстанда әлеге күрсәткеч 12219 сум тәшкил итә. Пособие билгеләгәндә гаиләдәге күчмә һәм күчемсез милеккә дә бәя бирелә. Мәсәлән, әти белән әни икесе ике машинада җилдерсә, аларга пособие юк. Ә гаиләгә туры килгән квадрат метрларны санаганда, өчтән бер һәм аннан да күбрәк өлеше шәхси милек булып саналган торак исәпкә алына. Ул яңа туган баланыкы булса да.

Пособиенең күләме дә аерыла. Акча гаиләнең керемнәренә карап, төбәктә бала өчен яшәү минимумының 50, 75 яки 100 проценты күләмендә билгеләнә. Гади тел белән әйткәндә, бүген әлеге төр пособиене алучылар бер балага күп дигәндә 11852 сум акча алырга мөмкин. Дәүләт ярдәме гаиләдәге һәр балага аерым түләнә. Узган елның 1 маеннан Пенсия фондына юллый башлаган гаризаларны кабат җибәрергә вакыт җиткән дә инде.

– Гадәттә, пособие, субсидияләрне озайту вакыты килеп җиткәч, Дәүләт хезмәтләре порталына яки электрон почтага бу хакта хат килә торган иде. Бу юлы сәлам бирүче дә булмады. Башка эшләр белән социаль фонд бүлекчәсенә баргач, очраклы рәвештә генә белеп, пособиегә кабат гариза яздым, – ди Яшел Үзән районының Күгеш авылында яшәүче дүрт бала әнисе Зәмирә Джороева.

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге мәгълүматларына караганда, бу хакта «сәлам хаты» килгәнне көтеп утырырга кирәкми.

– Әлеге төр пособие бер елга билгеләнә. Аны алга таба алу өчен Дәүләт хезмәтләре порталы яки күпфункцияле үзәк яки социаль фонд бүлекчәсенә килеп гариза язарга кирәк. Моны һәр әти-әни үзе хәл итә, – диде Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлегенең матбугат хезмәте җитәкчесе Альбина Никандрова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Быел балаларга пособие рәсмиләштерү өчен гариза язуга бәйле үзгәрешләр дә бар. Билгеле булганча, агымдагы елның 1 гыйнварыннан илдә йөкле хатын-кызларга һәм 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүче аз керемле гаиләләргә бердәм пособие гамәлгә керде. Ул моңарчы гамәлдә булган алты төрле түләүне, шул исәптән 8дән алып 17 яшькә кадәр балаларга пособиене дә берләштерде. Бер гариза ярдәмендә әллә ничә төрле түләүгә дәгъва кылып була, кыскасы.

– Тик киресе килеп чыкмасмы? – дип шикләнә Казанда яшәүче Гөлназ Шәйхетдинова. – Икенче улыма узган елның көзендә өч яшь тулды. Аңа 3тән алып 8 яшькә кадәр пособие рәсмиләштердем. Бер елга исәпләнгән акча быелның сентябренә кадәр киләчәк әле. Тик менә хәзер олысына бердәм пособиегә гариза язгач, мин эшкә чыгу сәбәпле, пособие түләүдән баш тартсалар, кече балага тиешле айлык акча да юкка чыкмасмы?

Болай дип фикер йөртүче әниләрне Социаль фондта тынычландырдылар.

– Бердәм пособиене гаиләдәге бөтен балаларга да бер үк вакытта (бу очракта моңарчы билгеләнгән айлык акча туктатылачак һәм бердәм пособие түләнә башлаячак. – **Ред.**) һәм һәр балага аерым рәсмиләштерергә дә мөмкин, – дип аңлаттылар фондның матбугат хезмәтендә. – Мәсәлән, Дәүләт хезмәтләре порталы аша бер генә балага документлар җибәрергә телисез икән, анкетада шул баланы гына күрсәтергә кирәк. Шәхси кабинетта кирәкле бөтен мәгълүмат бар инде, моның өчен тиешле урында тамга кую да җитә.

ГАИЛӘНЕҢ УРТАЧА КЕРЕМЕН НИЧЕК ИСӘПЛӘРГӘ?
Мисал итеп, Казанда яшәүче дүрт кешелек Галиевлар гаиләсен алыйк. Бер түбә астында әтисе, әнисе, 19 яшьлек студент кыз һәм 10 яшьлек малай яши. Аларның бер фатирлары һәм бер машиналары бар. Бу таләпләргә каршы килми. 2022 елның мартыннан 2023 елның февраленә кадәр әти – 500 мең, әни – 250 мең, студент кыз (стипендия рәвешендә) 15 мең сум акча алган. Әнә шуларның барысын бергә кушабыз да, бер елдагы айлар санына карап, уникегә, аннары дүрткә бүләбез. Нәтиҗәдә 15937 сум килеп чыга. Бу – гаиләнең бер айлык кереме. Ә ул Татарстанда җан башына туры килгән уртача керемнән зуррак. Димәк, Галиевлар бердәм пособиегә өмет итә алмый.

Былтыр 17 яшькә кадәрге балаларга пособие рәсмиләштерү өчен гариза тапшырган көннән дүрт айга артка чигереп, гаиләнең бер еллык керемен исәпләсәләр, хәзер бер айга гына артка «атлыйлар». Ягъни документларны бу айда тапшыручыларның 2022 елның мартыннан алып 2023 елның февраленә кадәр булган керемнәрен тикшерәчәкләр. Россия Хезмәт министрлыгы мәгълүматларына караганда, быел Татарстанда бердәм пособие түләүгә 18,7 миллиард сум акча тотылачак. Аның 11,2 миллиард сумы федераль бюджеттан бүлеп биреләчәк. Түләүне 150 мең чамасы кеше алачак дип көтелә. Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлегендә әйтүләренчә, гыйнвар башыннан бирле республикада яшәүче 50 меңгә якын йөкле хатын-кыз һәм 17 яшькә кадәр балалары булган гаиләләр бердәм пособиегә гариза тапшырган инде.

ТАТАРСТАНДА БЕРДӘМ ПОСОБИЕНЕҢ КҮЛӘМЕ (сумнарда)

	Яшәү минимумының 50 проценты	Яшәү минимумының 75 проценты	Яшәү минимумының 100 проценты
Йөкле хатын-кызларга	6659,50	9989,25	13319
Балаларга	5926	8889	11852

Россия Социаль фондыннан

Тузган торбалар яңартыла

Татарстанда коммуналь хуҗалыкны яңартуның федераль программасы буенча барлыгы 190 объект тәртипкә китереләчәк. Моңа 8,62 миллиард сумнан артыграк акча юллау күздә тотыла. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматларына караганда, быел бу эшкә федераль бюджеттан – 4,31 миллиард сум, Татарстан бюджетыннан – 2,91 миллиард, бюджеттан тыш чыганаклардан 1,4 миллиард сум җибәреләчәк.

Коммуналь инфраструктура Территорияләрне үстерү федераль фонды хисабына яңартылырга тиеш. Ләкин бер шарты бар: төбәк бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акча бирелгән очракта гына үзәк ярдәменә исәп тотып булачак. Бигрәк тә су белән тәэмин итү өлкәсендә күп эшләр каралган.

Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәгълүматлары буенча, республикада су-канализация хуҗалыгы оешмаларының төп фондлары 53 процентка тузган. 18,6 мең чакрым озынлыктагы су торбаларының – 5,9 мең чакрымын, 4,8 мең чакрым озынлыктагы канализация торбаларының – 1,8 мең, 3,4 мең чакрым озынлыктагы җылылык челтәрләренең 1,1 мең чакрымын алыштырырга кирәк.

Бушлай укыйлар

Соңгы ике елда «Демография» илкүләм проекты буенча 1,2 меңгә якын кеше Россия Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең Казандагы филиалында бушлай өстәмә белем алган. РАНХиГС филиалы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, 900дән артыграк кеше шунда үзләштергән белгечлеге буенча эшкә урнашкан инде.

Программалар өстәмә белем алу, шулай ук белгечләрнең квалификациясен күтәрү өчен билгеләнгән. Илкүләм проект буенча эшсезләр, бала карау ялындагы хатын-кызлар, 7 яшькә кадәрге балалары булган эшләмәүче аналар, 50 яшьтән өлкәнрәкләр, югары яки урта махсус белеме булмаган 35 яшькә кадәргеләр, шулай ук эштән җибәрелү куркынычы янаган кешеләр белем алырга мөмкин.

Быел республика хезмәт базары ихтыяҗларыннан чыгып төзелгән 16 программа буенча 400дән артыграк кешене укыту күздә тотыла. Барыннан да элек «1С-бухгалтерия программасы», «Смета эше», «Мәгълүмат иминлеге нигезләре. Персональ мәгълүматларны саклау», «Логистика», «Кадастр эшчәнлегендә заманча геодезия технологияләре», «Гид-экскурсовод», «Визажист» кебек һөнәрләрне үзләштерүгә ихтыяҗ зур.

Мөлкәттән коры калма

Татарстанда яшәүчеләрнең юл хәрәкәте кагыйдәләрен санга сукмаган өчен штрафлар буенча барлыгы 227 миллион сумлык бурычы җыелган. Хәзерге вакытта суд приставлары шундый әҗәтләр буенча 300 меңләп эшне карый.

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, Дәүләт автомобиль инспекторлары, бурычлыларның штрафны вакытында түләмәүләре сәбәпле, мәҗбүри түләтү өчен, приставларга административ эшләр җибәрә. Приставларга эш кергәч, бурычлы кеше 5 көн эчендә штрафын түләү хокукы ала. Аннан файдаланмаса, приставлар физик затлардан – 1000 сум, юридик затлардан кимендә 10 мең сум күләмендә өстәмә җыем түләтә. Болай да бурычын түләми икән, приставлар аларның мөлкәтенә арест салырга мөмкин.

Быел дүрт ай эчендә 100дән артыграк автомобиль хуҗасы, 1–2 көнгә генә булса да, җәяүлегә әйләнеп калган. Аларның «авто»сы, арест салынып, махсус стоянкага озатылган.

Һава торышы

Җылыткач салкынайтачак

Синоптиклар әнә шулай дип фаразлый. Россия Гидрометеоүзәге лабораториясе мөдире Людмила Паршина хәбәр иткәнчә, май аенда кар яварга да мөмкин.

Мурманск өлкәсе, Карелия, Ленинград, Псков һәм Новгород өлкәләрендә май яңгырлы булыр дип көтелә. Кырымда, Краснодар краенда, шулай ук Чиләбе, Курган, Оренбург, Новосибирск, Кемерово өлкәләрендә, Алтай краенда яңгырлар бик аз явачак. Мәскәүдә температура +19…+24 градуска кадәр күтәреләчәк. Белгечләр безгә дә шундый җылылык килер дип көтә. Кыскасы, май бәйрәмнәрендә Татарстанда 14 градустан алып 23 градуска кадәр җылы булыр диләр.

Татарстанның Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, бу атнада ук җылыта башлый. КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе доценты Тимур Әүхәдиев исә, никадәр җылы торса да, май аенда кырау төшү ихтималы булачак, ди.

– Соңгы вакытта климат үзгәрә, көйсезләнә. 1991 елдан алып Татарстанда начар һава шартлары булган көннәр артып кына бара. Шомырт чәчәк атканда, салкыннар булачак, – ди ул.

«ВТ»ның даими синоптигы – Балтач районының Яңгул авылында яшәүче Әмир Шәрәфиев ел фасылларының бик үзгәргәнен әйтте. Ел да кабатлана торган кайбер күренешләр булмаган.

– Климат үзгәрүе инде бу. Быел яз бөтенләй башкача килә. Иң элек гыйнвар аендагы хач ману суыклары булмады. Аннан соң хут суыкларын көттек. Ул да күренмәде. Язын карга бураны да, сыерчык бураны да булмады. Бик сәер әле бу, – ди Әмир абый. – Көннәр җылыта башлый инде хәзер. Әмма әле апрель аенда – бер, майда ике тапкыр суытып аласы бар. Әмма бу суыклар артык куркыныч булмаячак. Яңгыр булмау борчый мине. Күңелдә өмет бар. Көннәр җылытып алуга, ләйсән яңгыр явар дип көтәм. Ул бит карлар эреп бетүгә була торган иде. Туфракта дым аз. Бөтен үләннәр су көтә. Яңгыр кирәк.

Ни өчен бер көнне җылы төсле, икенче көнгә салкынайтып куя? Әмир абыйның җавабы кыска: яз урынына җәй баса алмый бит инде! Һәр фасылның бил бирәсе килми. «Кыш белән яз тарткалашкан кебек, җәй дә үз чиратын көтәргә мәҗбүр. Яз аңа әлегә ирек бирми, – ди Әмир абый. – Кар бетсә дә, туфрак җылынмады әле. Җир суык булгач, үлән үсми утыра. Бар да бер җылы яңгырдан тора. Ул явып китсә, янгыннар да кимеячәк».

Әмир Шәрәфиев фаразлавынча, быел җәй корылык та булырга мөмкин. Июнь – июль айларында озак вакыт яңгыр яумаячак.

– Явым-төшем мартта күп булды. Шуңа күрә быел яңгыр бик сирәк явачак. Июньдә эссе булачак, – ди халык синоптигы.

Сүз уңаеннан, Татарстанда 17 апрельдән 10 майга кадәр чүп ягу, шашлык пешерү бөтенләй тыела. Янгын кагыйдәләрен бозган өчен штраф каралган. Янгынга каршы режим кертелгән вакытта тәртип бозучы гади кешеләргә – 10 меңнән 20 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 30 меңнән 60 мең сумга кадәр, эшмәкәрләргә – 60 меңнән 80 мең сумга кадәр, юридик затларга 400 меңнән 800 мең сумга кадәр штраф салыначак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

cbr.ru

Эльвира НӘБИУЛЛИНА, Россия Үзәк банкы рәисе:

Быел без 5–7 процент инфляция булыр дип уйлыйбыз. Ләкин 2024 елда аны 4 процент дәрәҗәсендә тотарга омтылабыз. Бу, билгеле, икътисадтагы ставкаларга йогынты ясаячак.

(ТАСС)

РОССИЯДӘ – КИТАП УКУ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләрнең китапка мөнәсәбәтен белешкән. Соңгы өч айда кемнәр кулына китап алган икән?



57% >> китап укыган
40% >> бернәрсә дә укымаган
3% >> әйтергә кыенсынган

87% >> 18–24 яшьлекләр
49% >> 60 яшь һәм аннан да өлкәнрәкләр

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 10–20 апрель көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны
Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**
гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга
Ташламалы бәя **1051 сум 80 тиен**
гадәти бәясе – ~~1227 сум 30 тиен~~

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СУДАНДА ХӘРБИЛӘР БИЛ АЛЫША

Дөнья вакыйгалары кызу ага. Глобаль рәвештә блоклар төзү һәм Көнбатышка каршы берләшү бара. АКШ һәм аның аркадашлары да йоклап ятмый. Вашингтон Урта Азияне үз ягына аудару өчен тырыша. Зеленскийга Африка дәүләтләре белән уртак тел табарга киңәш итәләр. Украина конфликты тирәсендә Африка, Латин Америкасы, Азия дәүләтләре капма-каршы ике лагерьга берләшү юлына басты.

Бразилия Президенты Лула, Украина мәсьәләсендә арадашлык итү өчен, G20гә охшаган берләшмә төзергә чакыра. Искәртәбез: чит илләрдә Украинада махсус хәрби операция түгел, сугыш бара дип саныйлар. Лула төзергә теләгән «Зур егермелек»кә кемнәр керергә тиеш дип уйлыйсыз? Ул анда Латин Америкасы илләре, Кытай һәм Берләшкән Гәрәп Әмирлекләрен күрә. Конфликтны Кытай формуласы нигезендә тәгаллә теләргә теләгә тели. Көнбатыш моңа каршы. Каршылыкны хәл итәсе урынга яңа каршылык туачагы күзгә ташлана.

Дүшәмбе иртәсендә Сүриядә хәл кискенләшүе хакында хәбәрләр алынды. Фетнәче көчләр илнең төрле төбәкләрендә коралланган бәрелешләр оештырды. Президент Әсәднең ике якын туганы үтерелде, диделәр. Анда да Көнбатыш белән Россия – Иран көчләре үзара тартыша дип санала. Соңгы көннәр кан коешы АКШның махсус хезмәтләре тырышлыгы дип әйтүчеләр бар.

Шимбә көнне Африка дәүләте Суданнан кайнар хәбәрләр ява башлады. Илдә идарә 1919 елгы дәүләт түнтәрелешеннән соң хәрбиләр кулында иде. Хәер, 25 елдан артык идарә иткән элекке диктатор Әл-Башир да хакимлеккә хәрби түнтәрелеш нәтиҗәсендә килгән иде. Ил озак еллар буе милләтара конфликтлардан интекте, ахыр чиктә Көнбатыш дәүләтләренең тыкшыну нәтиҗәсендә икегә бүленде. Нефтькә бай Көньяк Судан аерылып чыкты. Илнең бөтен инфраструктурасы исә тәнъякта. Бүленү файдага булмады. Соңгы елларда анда Төркия, Мисыр, Россия кебек илләр үз мәнфәгатьләрен тормышка ашырырга тырышты. Рәсми рәвештә илдә хакимлек Суданның көчен суверен советы кулында дип санала. Аның рәисе Әл-Бурхан – хәрби, илдән читтә хәрби конфликтларда катнашкан кеше. Ил армиясе шуның якл. Әмма илдә тагын бер хәрби берләшмә – Тиз хәрәкәт итү көчләре дигән корал оешма, ягъни спецназ бар. Шул оешма шимбә көнне фетнә чыгарды, армия көчләренә һөҗүм итте. Хәер, алар, киресенчә, Судан армиясе һөҗүм итте, дип бар алар. Бәрелешнең беренче сәгатьләрендә Мөхәммәд Хәмдән – фетнәче көчләр лидеры: «Тиз хәрәкәт итү көчләре илнең 90 процент хәрби округларын үз кулына алды», – дип игълан итте. «Әл-Бурхан җир астында качып ята, Әл-Җәнийнә аэропорты алынды, Мисыр батальоны каршылыксыз бирелде», – дигән сүзләр таратты. Илдә кан коелды, БМО хезмәткәрләре арасында да үтерелүчеләр бар. Суданның башка аэропортлары да фетнәчеләр кулына күчте. Дүшәмбе иртәсендә Судан армиясе фетнәнең уңышсызлыкка очравы, Тиз хәрәкәт итү көчләренең чигенүе, уңышка ирешү өчен аларга һава көчләре һәм авыр техника житешмәве турында хәбәр итте. Бу юллар язылганда, кайсы якның уңышка ирешәчәге төгәл мәгълүм түгел иде әле.

Россиядә

ГАЗ САТМАСАК, ЛИТИЙ ТАБАРБЫЗ

Украина конфликты Россия икътисадын санкцияләр сызыгы рәвешендә дә кисеп үтә. Европа илләре, бер яктан, икенчел санкцияләр кертеп, Россиягә параллель импортны тыярга теләсә, икенче яктан, Россия чималын сатуга аяк чалырга тырышалар.

Нефть һәм газ державасы булган илне җиңел генә тышаулап булмый. Көнбатыш үзе дә мохтаҗ безнең углеводородларга. Россия ягулыгын Африка, Азия, Якын Көнчыгыш илләре аша алырга мәҗбүр. Әмма санкцияләрне тулысынча тормышка ашыру һәм җиренә житкерү өчен эзлекле көраш бара. Соңгы көннәрдә Европа Берлегендә Себер сыекландырылган газын сатып алудан туктау турында сөйләшәләр. Юк, әлегә эмбарго кертергә ук җыенмыйлар, киңәшләр генә. Ләкин Нидерландның энергетика министры Роб Йеттен әйткәнчә, хөкүмәт гамәлдәге контрактларны өзәргә җыена. Испания премьер-министры Тереза Рибера да хосусый компанияләрне Россия сыекландырылган газыннан баш тартырга өндәде. Үткән көннәрдә Европа Россия газын кулланмады диярлек, туңмады, бәяләр да күтәрелсәсе урынга төште. Хәзер газга яңа һөҗүм башларга җыеналар.

2022 елда Көнбатыш 16,5–7,5 миллион тонна (кубометрга күчергәч, 23–24 миллиард кубометр) сыекландырылган Себер газын алган. 2021 елга караганда 20 процентка күбрәк кулланган. Хәзер шуннан баш тартырга телиләр. Россиядә барысы 33 миллион тонна сыекландырылган газ җитештерелә. Бу уңайдан «Российская газета»: «…потеря европейского рынка может быть весьма чувствительна», – дип яза. Газ алучылар табылыр ул, ләкин транспортлау чыгымнары артыр, бәяне дә төшерергә туры килер. Белгечләр шулай да сыекландырылган газдан эмбарго рәвешендә үк баш тарту булмас дип уйлыйлар. Европалылар бәя төшергә теләп кенә шулай кылана, дип әйтүчеләр дә бар.

Россиядә газ һәм нефть кенә түгел, кыйммәтле чималның башка төрләрен дә табарга ниятлиләр. «Икътисадның яңа нефте» дип аталган литий чыгаруны җайга салмакчылар. 2021–2022 елларда литийга бәяләр 8 тапкыр диярлек үскән. Бу әлеге металл чыгаруны рентабельлегә әйләндерәчәк, диләр. Моңарчы Россия аны Аргентина, Чили һәм Боливиядән импортлый иде. Аргентина һәм Чили үткән ел литийны Мәскәү тарафларына озатудан баш тарттылар. 80 процент импортка алмаш табу ихтыяҗы туды. Бер Боливия генә барлык импортны тәэмин итә алмый. Литийдан башка югары технологияләр юк. Россия үзе литийга бай илләрдән санала. Аны катлам сулуннан алу арзангарак та төшә. Ләкин проблемалар бар. Экологик яктан зыянлы проект бу. Аннан соң литийны чыгару гына түгел, икенчел эшкәрту, әзер продукта, кулланырга яраклы товарга әйләндеру таләп ителә. Бу – технологияләр һәм инвестицияләр дигән сүз. Киләчәктә металлның бәясе төшү дә ихтимал. Барлык уңай һәм тискәре якларын үлчәгәч, яңа проект тормышка ашырыла башлар, дип көтелә.

ЯБЫК КАПКА

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

«Күрергә теләмәгән зат». Молдовага эш сәфәре белән барган Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановны әнә шулай дип кире борганнар. Республика башлыгы Кишиневта очкычтан да чыга алмыйча, кайтып китәргә мәҗбүр булуы турында үзе сөйләде.

Молдовада Рөстәм Миңнеханов «Халыклар дуслыгы – 2023» I Халыкара халыклар дипломатиясе конгрессында катнашырга тиеш иде.

– Әле күптән түгел генә Татарстанда булып киткән Виктор Петров (Гагаузия халык җыены депутаты, төбәк башлыгы вазыйфасына кандидат) һәм Александр Суходольский (Молдова парламентында Гагаузиядән депутат) белән бергә киңкырлы уртак эшчәнлек программасы билгеләдек. Кызганыч, Молдова хакимияте безне күрергә теләмәгән затлар дип билгеләде һәм ил чиген узарга рөхсәт итмәде. Шуңа күрә конгресс эшендә катнаша алмыйбыз, – диде ул очкычта төшерелгән мөрәҗәгатендә.

Рәис белән бергә Кишиневка «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционерлык оешмасы генераль директоры Иван Егоров та барган иде. Александр Суходольский белдергәнчә, Татарстан вәкилләренә очкычтан төшәргә дә рөхсәт итмәгәннәр. Моңа да карамастан, Татарстан Рәисе гагаузларны Пасха бәйрәме белән котлады һәм Виктор Петровка эшендә уңышлар теләде.

– Татарлар һәм гагаузлар – тугандаш халыклар. Соңгы елларда ике арада элемтә урнашты, алдагы үсеш өчен үзара ярдәмләшүгә бәйле планнарыбыз да бар. Виктор Петров җитәкчелегендәге яшь команда, бер яктан, Россия һәм Татарстан, икенче яктан, Гагаузия арасында ныклы бәйләүче буын булыр дип ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, Гагаузия – Молдованың көньягындагы автономияле төбәк. Аларның күбесе – православ христианнар булган төркиләр. Гагаузлар, 1800 нче елларда Госманлы төрекләренең эзәрлекләүләреннән качып, хәзерге Молдовага килеп урнашкан, дип фаразлана.

Бу елның мартында Виктор Петров җитәкчелегендәге Гагаузия делегациясе Казанга килде. Автономия вәкилләре Рөстәм Миңнеханов белән сәүдә-икътисадый элемтәләрне ныгыту һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек итү турында фикер алышты.

Әлеге уңайдан Молдова хакимияте берниндидә рәсми аңлатма бирмәгән.

ФЕРМЕРЛАРГА – ЯШЕЛ УТ

Авыл киләчәге

Тәвәккәлләргә бервакытта да соң түгел! Хуҗалыгын агротуризм юнәлеше буенча җәелдерергә ниятләүче Балтач районының Салавыч авылы егете Азат Борһанов сүзләре бу. Узган ел ул, юл төзелеше тармагына бәйле эшен калдырып, кош-кортлар алып, авылга кайтып төпләнергә карар кылган.

Татьяна Кированың шәхси архивыннан

Хәзерге вакытта Азат эшчәнлеген шәхси хуҗалык башлыгы буларак алып бара, киләчәктә фермер булырга әзерләнә. Ямь-яшел болында йөрүче йөзләгән сарык, унлап сыер, кәҗә, кош-корт һәм шунда ук халыкка кереп ял итәр өчен зур булмаган авыл йорты. Үзенең туристлык утарын Азат әнә шулай күзаллый. Хәер, тәвәккәл егет моның белән чикләнеп калырга теләми. Киләсе елларда бирегә ук барысы да: сыры да, колбасасы, эремчеге, каймагы да эшләнәчәк.

– Хәзерге вакытта мин басу өчен җир рәсмиләштереп йөрим, – ди ул. – Киләчәктә кунаклар шушында килеп ял итә алачак. Бирегә үк яңа гына эшкәртелгән иттән шашлык кыздырып ашау мөмкинлеге дә булачак. Сентябрь аенда Агростартап программасында катнашыр өчен, гариза тапшырырга ниятлим.

Азат Борһанов әйтүенчә, туристлык хуҗалыгы ике юнәлештә эшләячәк. Бер өлешендә авыл, район кешеләре туганнары, гаиләләре, дуслары белән килеп ял итсәләр, бераз читтәрәк вип-зона булдырылачак.

Киләчәктә эш урыннары да тәкъдим итмәкче Азат.

– Районда агротуризм юнәлеше буенча эшләүчеләр булса да, бик сирәк. Мин моның уңышлы булуына өметләнәм. Күпчелек кешенең хәзер ял итәр өчен чит илләргә барырга мөмкинлеге юк. Акчасы булса, вакыты табылмый. Ә бирәдә ул гаиләсе белән рәхәтләнеп ял итеп китә алачак. Зур терлек, куян ите, йомырка, сөт, эремчек, каймак, сыр – барысы да үзебездә булачак. Ферманы зурайту турында уйлаганмыйм, иң мөһиме, сыйфатка эшләргә телим, – ди ул.

Азат Борһанов – Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Россельхозбанкның уртак проекты булган «Фермер мәктәбе» укучысы. Шушы көннәрдә ул, мәктәпнең иң яхшы укучысы буларак, кулына сертификат алды. Быелгы проектта «Терлекчелек» һәм «Кошчылык» юнәлеше буенча 40 укучы катнашкан.

Шулай итеп, «Фермер мәктәбе»нең өченче чыгарылышы булды. Иң яхшылар дип билгеләп узылган тагын ике укучы проектларын кошчылык юнәлеше буенча яклаган. Беренче чыгарылыш студентлары да сынатмый: бүген алар эшчәнлекләрен уңышлы алып бара. Әйтик, Яшел Үзән районының Зур Ключи авылында яшәүче Татьяна Кирова зур хуҗалыгында тавыклар, күркәләр, мисыр тавыкларын, фазаннар, казлар, сарыклар, кәҗәләр һәм атлар үрчетә.

Татьяна Кирова әйтүенчә, аның һәр сәгате санаулы. Инкубаторда чебиләр чыгару, терлекләрне ашату, сарайларны җыештыру, йомыркаларны җыеп алу булсынмы – барысына да эшмәкәр ханымның ныклы контроле кирәк. Әлеге вакытта «Светлая ферма» фермер хуҗалыгы терлек һәм кош-кортларны үрчету белән генә түгел, ә итләрне эшкәрту белән дә шөгыльләнә.

– Башта мин итне сатып кына җибәрермен дип уйлаган идем, тик тора-бара эшкәртүгә күчтем. Ярымфабрикатлар ясый башладым, хәзер инде продукциямне Мәскәүгә кадәр алып китәләр, – ди ул.

Хәзерге вакытта фермер 60ка якын төрдәге продукция җитештерә. Һәм үзенең уңышларында «Фермер мәктәбе»нең дә өлеше зур дип саный.

– Әлеге уку минем фикерләвемне тулысынча үзгәртте, – ди Татьяна Кирова. – Анда мин өстәмә белем алып, аларны эшчәнлегемдә кулландым, бөтенләй башка төрле уйлый башладым. Укудан соң беренче чиратта сыйфат артты, ә сан инде шуңа ияреп үсте. Остазлар белән бергә үстерү ысулларына кадәр өйрәндек. Нәтиҗәдә, «Фермер мәктәбе»нә кадәр сезонга 50 баш каз үстерсәк, укудан соң аларның санын 260 башка кадәр җиткердек. Моннан тыш, сөтчелек-итчелек юнәлешен дә өйрәндем, киләчәктә бу белемнәрем сарыклар һәм кәҗәләр үрчетер өчен кирәк булды. Проектта катнашкан башка фермерлар белән дә һәрдаим элемтәдә торабыз. Киләчәктә, балки, барыбыз да берләшеп, авыл хуҗалыгы кооперативы да булдырырбыз, дип өметләнәм.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Ярдәм

Яшермә син зарларыңны

Хәрби хәрәкәтләр зонасында катнашкан кешеләрнең саулыгы аерым игътибарга мохтаҗ. Психик сәламәтлеккә зыян килү дигәне дә бар. Шуңа күрә вакытында белгечкә күренү кирәк. Дәүләт Думасының сәламәтлек саклау буенча комитет рәисе Дмитрий Хубезовның бу җәһәттән «Парламентская газета»га биргән әңгәмәсендә шуңа басым ясалган.

– Хәрбиләр, яраланган булса, кимендә бер мәртәбә психолог белән сөйләшергә тиеш. Бу ярдәм шундук күрсәтелергә тиеш. Мәсьәләнең тагын бер ягы – профилактика. Әйтик, хәрбинең яралары юк, физик зыян килмәгән, әмма билгеле бер зарлары бар. Аларны вакытында ачыклау мөһим. Монда төп проблема – психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләрдә. Күбесе мөстәкыйль рәвештә психологларга килергә оялә. Соңгы исәпләүләр буенча, махсус хәрби операциядә катнашучыларның ике проценты гына мөстәкыйль рәвештә терапевтка ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән, – дигән фикердә Дмитрий Хубезов.

Мәсьәләне ике төрле юл белән хәл итеп була, дип саный бу комитет башлыгы.

– Беренчедән, андый егетләргә диспансеризация вакытында аерым игътибар бирергә кирәк. Әйтик, махсус халыкара сорашттыру анкетасын тутырууларын сорарга (CAPS). Бу – җәрәхәтләнү арасында кичергән стресска бәйле тайпылышларны ачыклау шкаласы. Нәтиҗәдә аларга психиатр, психолог ярдәме кирәкме-юкмы – шуны ачыкларга мөмкин. Икенче юл – мондый анкеталарны почта аша җибәру. Хәрби хезмәт килешүе төзегәндә, алар шушы сорашттыруны узарга тиеш була.

Дмитрий Хубезов сүзләренә караганда, махсус хәрби операциядә катнашучылар, нерв системасына бәйле зарлары булган очракта, гомуми клиникага түгел, ә турыдан-туры махсус үзәкләргә эләкә, күпкә яхшырак булыр иде. Андый үзәкләрдә табиблар тиз арада ярдәм күрсәтәчәк.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Әхмәтҗанов** Ислам Галиәхмәт улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Маяк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Ахтонов** Алексей Александрович, «С.Ш. Гыйниятуллин исемендәге племрепродуктор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Гыйниятуллин** Сәгыйть Шәрифулла улына, «Димитриев Роберт Павлович» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Димитриев** Роберт Павловичка, «Ярыш» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте машина йөртүчесе (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Мәрданов** Марат Миңнерәис улына, «ЧИРМЕШӘН-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Чирмешән районы) **Назыйров** Ирек Фәткелҗан улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге әйдәүче белгече **Толочко** Елена Юрьевнага, «Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте комплексы башлыгы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Хаҗимҗәтова** Гөлфия Равил кызына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы урынбасары **Харисов** Марат Мансур улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Дәүләт Советы депутатларына игътибарына

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык өченче утырышы 20 апрель көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында уткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 20 апрельдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

САТУЧЫГА ДА, АЛУЧЫГА ДА БӘЙРӘМ

Үзем күрдем

Казанда язгы ярминкәләр гөрли. Узган шимбәдә авыл рәтләре арасыннан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та узды. Ул авыл хезмәтчәннәренә рәхмәтен җиткерде. Халык кәефе нинди, кайсы ризыкларны яратып алалар? «ВТ» хәбәрчесе дә шимбә иртәсен авыл мохитендә уздырды.

Бу атнада «Казан» агропаркына Мамадыш, Кукмара, Арча районнары уңганнары килеп, үз продукциясен тәкъдим итте. Тышкы яктагы мәйдан әллә каян үзенә тартып тора. Ул көнне бирәдә тормыш кайный. Еракларга җырмоң тарала, әтәч кычкырган тавышлар ишетелә, ит кыздырган ис чыга…

Мамадыш районының иң тәмле ризыкларын алып килгән: май, сыр, лимонад, казылыклар… Пешкән ризыклар, ярмалар да җитәрлек. Читтәрәк балык сатучылар тезелгән. Алардан соң авыл җирлекләрендә яшәүчеләр сату итә. Берәүләр кул эшләрен сата, икенчеләр юкадән мунчала ясап китергән, өченчеләр кышка әзерләгән банка-банка сый-нигъмәтен алып килгән.

– Ярминкәләрне көтеп торабыз. Районда узганына да барырга тырышабыз. Монда үзенә күрә бер җыелышлык бар. Казанга бару мәртәбә инде ул. Шәһәр халкының ихтыяҗын өйрәнеп кайтасың, – ди Мамадыш районның Түбән Яке авылы җирлеге башлыгы Рафаэль Низаметдинов.

Каршы якта арчалылар сәүдә итә. Алар да үзләренең халык яратып алган ризыкларын алып килгәннәр. Бирәдә литрлап сатыла торган сөткә чират тезелгән. Наласа авылыннан Фәрит абый сарымсак, йомырка, литр ярымлы шешәләрдә сөт алып килгән.

– Йомырканың дистәсен 100 сумга сатам. Сөтнең шушы шешәсен 100 сум дип торам. Халык бик сорагач, 90га да биреп җибәрәм. Бәяне төшерәсем килми. Шәһәр кешесе сөтне җиңел генә савып алабыз дип уйлыйдыр инде. Имчәкне юасың да, сөт чыга, дип. Әмма сыерны сыер итәр өчен дә, сөтен савып алыр өчен дә күпме тырышасың бит! Мал тотканнар яхшы белә. Хәзер бит барысын да сатып аласы. Печәне дә, ашлыгы да кыйммәт, – ди Фәрит абый. – Сарымсакның килосын 250 сумга алып китәләр. Берәү дә артырамый. Ә бит хезмәте дә аз, чыгымы да.

Кукмаралылар рәтендә дә зур чиратлы урыннар күп иде. Борай ярмасына тезелешкәннәр, сөткә, иткә…

– Бирегә 4 елдан артык йөрим инде. Халык продукциябезне бик яратты. Инде үз клиентларым бар. Килүемне көтеп торалар. Язгы-көзге ярминкәләрне барышында бер генә шимбә дә килми калмадым. Нинди һава торышы булмасын, кешеләрне уйлап, юлга чыгып китәм. Атна буена җитәрлек итеп алып куючылар бар бит, – ди Рифнур Шакиров. – Мондый ярминкәләр бик кирәк. Безгә дә файда. Кешеләр белән аралашып кайту да рәхәт. Киләчәктә дә шәһәр халкын сөендерер торырга язсын!

Илшат Хамизов та шактый еллар бирәдә ит сата. Яшерми, районда уза торганнарында да сатып караган. Әмма Казанда табышлырак, ди.

– Яңа гына чалган мал ите булгач, тиз алып бетерәләр. Ит янына бавырын да, йөрәген дә алып китәм. Мал аякларын сораучы бар. Халык бик иртә йөри. Узебез дә иртәгә ярминкә дигән төнне йоклап тормыйбыз, иртәнге өчтә юлга чыгабыз, – ди ул.

Кабат рәтләр буенча узам. Сатып алучыларны коймак белән дә сыйлыйлар икән бирәдә. Шунда чәйләп алучылар белән дә сөйләштем. Наилә апа бер генә ярминкәне дә калдырмаган.

kzn.ru

БӘЯЛӘР (сумнарда)	
Сыер ите (кг)	430–480
Бавыр (кг)	350–400
Атланмай (кг)	520–550
Йомырка (дистәсе)	100
Сөт (литр)	40–50
Сыр (кг)	350–430
Бәрәңге (кг)	18
Кәбестә (кг)	14
Суган (кг)	55

– Атна саен килеп, запас туплыйм. Пенсия начар түгел. Монда әйберне кыйммәт сатмыйлар. Акча да янга кала, сыйфатлы ризык та аласың. Автобус белән йөргәч, күп әйбер күтәреп булмый. Кыяр-помидор алам, чәйгә пироглар, кәбестә дә алдым әле бүген. Итләрне өйгә китереп бирделәр. Акчасын түләп киттем дә, китерделәр. Бәрәңгене дә шулай иттеләр, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

Узган атнада фермерлар барлыгы **10** млн сумлык продукция алып килгән. Бу – **40** тонна бәрәңге һәм яшелчә, **10** тонна шикәр, **8** тонна сыер ите һәм он, **4,5** тонна сөт, **4** тонна ярма, **1,2** тонна май, **1** тонна кош ите, **1** тонна сыр һәм **32,4** мең дана йомырка дигән сүз. Авыл хуҗалыгы ярминкәләре шулай ук Чаллыда, Яшел Үзән районында һәм Түбән Камада үткәрелә. Татарстанда **18** марттан **8** апрельгә кадәр сәүдә мәйданчыкларына **253,5** млн сумлык товар китерелгән.

22 апрельдә язгы ярминкәнең соңгысы узачак.

ТЫНГЫСЫЗ ЙӨРӘК

Югалту

Узган атна шимбәсе Татарстанның матбугат дөньясына күңелсез яңалык алып килде. 54 яшендә «Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе урынбасары, Татарстан Президенты матбугат хезмәтенең элеккеге җитәкчесе Эдуард Хәйруллин вафат булды.

vk.com

Хәзер, аны һич тә вазыйфаи зат буларак кына тасвирлап булмый. Эдуард Фәрит улы, иң беренче чиратта, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан һәм Казан тарихын сөюче зыялы шәхес иде. Андый шәхесләрне югалту һәрвакыт авыр. Моны хушлашу мәрасимендә дә кат-кат искәрттеләр. Аның турында үткән заманда сөйләү дә табигый түгел әле…

Эдуард Хәйруллинны соңгы юлга озату мәрасимен Татарстан Журналистлар берлеге рәисе, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов алып барды. Берничә көн элек кенә сөйләшүләрен, хезмәттәшебезнең гадәттәгечә максат-планнарга бай булуын телгә алды ул.

– Теләсә кайсы үлем – фаҗига. Әмма вакытсыз югалту – меңләтә авыр. Без, бирегә җыелганнар, әле дә Эдуардның юклыгына ышана алмыйбыз, – диде Илшат Әминов. – Мин аны эшкә алган көнемне әле дә хәтерлим. Ул тиз арада аудиториянең яраткан кешесенә әйләнде. Аның тарту көче бар иде. Интеллигент, игътибарлы булуы, йомшак көче белән үзенә карата белде. Эдуард һәрвакыт эзләнүчән иде.

Бу сүзләрне дәлилләп, Илшат Әминов бакыйлыкка күчкән шәхеснең саллы эшләрен санап китте: Зөя утрау-шәһәрчегенә багышланган фотоальбом чыгару, «Татарский с Дмитрием Петровым» проектында катнашу, Ушкова йорты хуҗасының каберен табу, шул йортта экскурсияләр оештыру…

– «Казанда шулкадәр яңалык, тарихи фактлар күп! Сез әле белмисез! Барыгыз да шаккатачаксыз!» – дигән иде Эдуард. Кызганыч, өлгермәде… Моны аңлау һәм кабул итү шулкадәр авыр… – диде Илшат Әминов.

«Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев тә Эдуард Хәйруллинның вафат булуын коллектив өчен дә, медиа тармагы өчен дә көтелмәгән булуын әйтте.

– Эдикның төп сыйфаты яраттыра, үзенә гашыйк итә белү иде. Үзе дә ярата белде ул. Соңгы елларда ул тарих белән бик кызыксынды. Бу аның иң зур мәхәббәте булгандыр да. Казанны, аның кешеләрен яратты. Башкаланың матурлыгын башкаларга да сөйлисе килде – өлгермәде, – диде Айдар Сәлимгәрәев. – Эдуард Хәйруллинның бөтен нәрсәсе бар иде. Тик бер генә нәрсәсе булмады: үзен кайгырта һәм саклый белмәде.

Татарстан Рәисе ярдәмчесе Олеся Балтусова Эдуард Хәйруллинны тормыш энергиясе күп булган кеше буларак истә калдырачагын әйтте.

– Эдуард – мирас дөньясына килеп кергән һәм ул мирас турында ничек итеп сөйләргә кирәклеген күрсәткән кеше. Аның тормыш энергиясе күп иде. Ярдәмче һәм берләштерүче иде ул, – диде ул. – Эдуард изге көнне китеп барды. Без сине саклап кала алмадык, кадерлебез. Безнең белән булганың өчен рәхмәт сиңа!

Зөя утрау шәһәрчеге музей-тыюлыгы директоры Артем Силкин Эдуард Хәйруллинны дус буларак кына түгел, сәяхәтче буларак та белә.

– Без бик күп шәһәрләргә бергә йөрдек. Ул бик йомшак, тәрбияле кеше иде. Мондый сыйфатлар бик кадерле. Ул Свияжскида яшәгәндә, бергә тордык. Балаларыбыз бергә мәш килде. Китаплар укый идек. Эдуард бик якты кеше булды. Җитәкче вазыйфасында булса да, кешелеклелеген югалтмады, үзенә хыянәт итмәде, – диде ул.

Соңгы сүзне исә улы Тимурга бирделәр.

– «Әти юк» дип сөйләргә бик авыр. Минемчә, иң мөһиме – аны якты кеше итеп истә калдырулары. Бу көч бирә. Ул моңаюыбызны теләмәс иде. «Күңелсезләнү – гөнаһ», – дия иде. Ул үзендәге яктылыкны башкаларга да бүлеп бирде. Күп нәрсәне эченә җыйды. Әти исән, әти безнең традицияләрдә, без бергә атлаган сукмакларда яши. Мин сине яратам, әти! – диде ул.

Эдуард Хәйруллин үтә дә тыныч, әмма тынгысыз кеше иде. Тыныч кына китте дә. Эдуард Фәрит улын Тынычлык бистәсендә җирләделәр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Рәисе:
– Танылган журналист һәм оста җитәкче, илнең төп телеканалларында һәм республиканың төрле җаваплы вазыйфаларында күп еллар буе хезмәт куйган профессионалның, гүзәл кешенең арабыздан мәңгегә китүен аңлау бик кыен. Эдуард Хәйруллинның сирәк очрый торган гаҗәеп таланты, күпкырлы мәнфәгатьләре, тормыштагы актив позициясе һәм күңел көрлеге зур иҗтимагый һәм агарту эшчәнлегендә, бик әһәмиятле иҗади һәм мәдәни проектларында ачык чагылды. Ул үзен якыннан белүчеләрнең күңелендә гаять зыялы, рухи яктан бай, һәрвакыт яңаны булдыру юлыннан барган бик актив кеше буларак уелып калачак.

Минтимер ШӘЙМИЕВ, Татарстанның Беренче Президенты:
– Эдуард Фәрит улын «Беренче канал»да, шуннан соң Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе булып эшләгән чагыннан бирле әйбәт беләм. Соңгы вакытларда ул «Новая Тартария» дигән искитмәле проекты белән игътибарыбызны җәлеп итте. Күпьеллык хезмәттәшлегебез изге мөнәсәбәтләргә һәм үзара аңлашуга корылган. Ул бик яхшы журналист, үз эшенә тугрылыклы профессионал, иҗади фикер йөртүчән, киң эрудицияле кеше иде. Эдуард Фәрит улы изге күңелле, максатка омтылышлы кеше буларак күңелләребездә мәңгегә сакланачак.

Әсгать СӘФӘРОВ, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе:
– Медиа өлкәсенең иң лаеклы вәкилләреннән берсе, үз эшенең остасы, үзенчәлекле һәм гаять талантлы кешенең кинәт вафат булуы тетрәндерде. Эдуард Хәйруллин истәлегенең күпсанлы хезмәтләрендә – туып-үскән шәһәре һәм республикасына багышланган тиңдәшсез фотолары, тарихи китаплары һәм видеоэкскурсияләрендә мәңгегә сакланып калачагына иманым камил.

Рөстәм НИГЪМӘТУЛЛИН, Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары:
– Ул чын патриот һәм югары профессиональ журналист буларак безнең республика файдасына эшләде. Ул һәрвакыт кешеләр белән кызыксынып аралашты, һәркем белән уртак тел тапты. Аралашуда җиңел булды, тәрбияле, фикерле иде һәм үз фикерен яклый белде. Аның тормышка ашырырга теләгән проектлары бик күп иде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары

ХӘЙРУЛЛИН Эдуард Фәрит улының

гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Эдуард Хәйруллинның кинәт кенә арабыздан мәңгегә китүе бөтен республика җәмәгатьчелеген тетрәндерде. Талантлы журналист, үз эшенә тугрылыклы, югары дәрәҗәдә квалификацияле җитәкче, туып-үскән шәһәренең тарихы белән кызыксынган бетмәс-төкәнмәс энергияле кеше иде. Эдуард Фәрит улы 15 елдан артыграк вакыт дәвамында дәүләт хезмәтендә эшләде. 2015 елдан 2019 елга кадәр Татарстан Республикасы Президентының матбугат хезмәтенә җитәкчелек итте.

Эдуард Фәрит улы Хәйруллинның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары

ХӘЙРУЛЛИН Эдуард Фәрит улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар

АГАЧ ЙОРТЛАРДА – МӘДӘНИ ХӘТЕР



Дөньяда ЮНЕСКО химаясенә караган алты агач шәһәр бар. Агач төзелеш архитектурасын саклау проблемасы Россиянең күп кенә шәһәрләре өчен актуаль. Тарих һәм мәдәниятнең кыйммәтле катламы буларак, агач төзелеш Татарстанның төбәк-милли традицияләрен үстерү мөмкинлекләренең зур потенциалын тәшкил итә. Казанның, Татарстанның кече шәһәрләре һәм авылларының агач төзелеш архитектурасының бай мирасы Равил Сәйяр улы Айдаровның акварельләре аша җиде томлы архитектура-сәнгать альбомнарында тәкъдим ителгән.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты үзенең график модельләштерү кафедрасы профессоры, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган архитекторы Равил Айдаровны Татарстан Республикасының агач төзелеш сәнгатенә багышланган җиде томлы альбомнар сериясе өчен Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим итә.

Советлардан соңгы яңа чорда тарихи үзәкне реконструкцияләү нәтиҗәсендә иске Казанның агач төзелешенә караган кварталлары күпләп сүтелә башлый. Шул вакытта Равил Сәйяр улы, рәсемнәрендә бер-бер артлы тузган, ярым ишелгән яисә бөтенләй югалган йортларның архитектурасын торгыза барып, архитектура акварельләрен ясауга керешә. Нәтиҗәдә ул үзенең акварельләрендә иске Казанның сүтелә, җимерелә баручы урамнарының йөзен саклап кала, юкка чыккан милли мирас объектлары чагылыш тапкан картиналар сериясен булдыра. Соңгы елларда Равил Айдаров, авыл агач төзелеше мирасын һәм традицияләрен урыннарга барып өйрәнү, үзенең архитектура акварельләрендә төрле типтагы агач корылмаларны җентекләп сурәтләү максатында, Татарстанның кече шәһәрләренә һәм төрле районнарындагы авылларга бара. Урыннарда агач йортларны һәм аларның бизәлеш детальләрен җентекләп өйрәнә һәм рәсемнәрен ясый, нәтиҗәдә төгәл итеп сурәтләнгән архитектура-сәнгать акварельләре пәйда була.

Җиде томлы архитектура-сәнгать альбомнары сериясендә авторның 800дән артык уникаль акварель тупланган. Аларда иске Казанның агач йортлары, чиркәүләре, мәчетләре, җәмәгать биналары һәм урамнары, шулай ук Татарстан Республикасының кече шәһәрләре һәм авыллары архитектурасындагы агач төзелеш традицияләре чагылдырылган. Казанның, кече шәһәрләрнең агач төзелеш архитектурасы мирасының башкалада һәм аннан читтәрәк урнашкан объектларында, Татарстанның бүгенге агач авыл йортларында чагылыш тапкан милли-төбәк үзенчәлеге зур һөнәри осталык белән, чынбарлыктагыча, җентекле детальләренә кадәр сурәтләнеп бирелгән.

Равил Айдаров акварельләрендәге борынгы йортлар, мәчетләр, Казан урамнары – барысы да бөек Габдулла Тукайның замандашлары. Шагыйрь бу урамнар буйлап йөргән, Иске Татар бистәсенең рухи атмосферасын тудырган бу йортларны күргән. Иске Татар бистәсендәге агач йортлар һәм урамнар үзләренә генә хас сыйфатлары, билгеләре белән шәһәрнең башка урыннарыннан шактый аерылып торган. Татар торак кварталын утар һәм күпфатирлы йортлар тәшкил иткән. Алар үз чиратларында шулай ук планлаштырылулары, тышкы кыяфәтләре, декоратив бизәкләре һәм үзләренә генә хас төсләр төрлелеге белән аерылып торган. Болар барысы да Равил Айдаровның архитектура акварельләрендә җентекләп сурәтләнгән. Равил Сәйяр улы Айдаров фикеренчә, үзендәге күп кенә агач йортларның юкка чыгуыннан зыян күргән «Иске Татар бистәсе» тыюлыгы тарихи төзелешенә хас төп төрләрне торгызу юлы белән яңа сулыш ала алыр иде: әйтик, берәр урамны, берәр кварталны, ишегалды корылмалары да булган берәр татар утарын торгызу аша.

Равил Айдаровның җиде архитектура-сәнгать альбомында борынгы урамнар, көнкүреш күренешләре иске шәһәргә, Татарстанның кече шәһәрләренә һәм авылларына зур мәхәббәт белән сугарылган. Алар Идел буенда урнашкан шәһәребезнең, татар авылының җылылыгын, анда кайнаган тормышны тоярга мөмкинлек тудыра.

Рәсемнәрдә төрледән-төрле биналар, аларга хас архитектура детальләре бирелгән. Күргәзмә, бакча-парк һәм тукталыш павильоннары, биек триумфаль аркалар, трактир, кунакханә, хастаханәләр, цирк, җәйге театр, күперләр, пристаньнар һәм башкалар – бүген боларны агачтан төзү мөмкин дә түгел кебек. Ләкин алар булган һәм юкка чыкмаячак – Равил Айдаров иҗаты аша безнең белән калачак.

Шәһәр үзенең киеренке эш көннәре, үзенә хас ритмнар белән яши, иртәгәсе көнгә ышаныч белән карый. Яңалыклар тормышыбызга гел үтеп кереп тора, аны тагын да төрлерәк һәм кызыклырак итә, әмма, ачыкланганча, кешеләргә хәзерге заманның тотрыклылыгын тою гына түгел, узганнарны хәтерләү дә мөһим икән. Иске Казаннан башка, яңасын танып булмый, бу инде башка шәһәр булачак. Әлбәттә, юкка чыккан, сүтелгән агач торак һәм җәмәгать биналарыннан тыш, күп кенә борынгы кирпеч йортлар, мәчетләр, чиркәүләр, зур җәмәгать корылмалары сакланып калган, шул ук вакытта, Равил Айдаровның хезмәтләре күрсәткәнчә, Идел буендагы губерна шәһәре саналган иске Казандагы төзелешнең 70 процентын утар һәм күпфатирлы йортлардан, җәмәгать һәм дини биналардан торган агач урамнар һәм кварталлар тәшкил иткән. Аларның бөтенесен дә саклап калып булмый, ләкин алар мәдәни хәтердән җуелырга тиеш түгел.

Равил Сәйяр улы Айдаров – профессор, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының график модельләштерү кафедрасы педагогы. Иске Казанның агач урамнарын күрмәгән студентлар мөгаллимнәренең рәсемнәре аша да бу таныш булмаган шәһәрдә нинди тормыш кайнаганын аңларга тырыша. Татарстанның агач төзелеш архитектурасы – киләчәк буыннарга тапшырылырга тиешле мәдәни код ул.

Равил Сәйяр улы Айдаровның китап-альбомы кебек хезмәткә тиң эшләр юк. Аларда Казанның, Татарстанның кече шәһәрләре һәм авылларындагы торак, җәмәгать һәм дини биналар сурәтләнеп, барлык объектлар буенча кыйммәтле мәгълүмат бирелгән уникаль архитектура-сәнгать эшләре беренче тапкыр басыла. Альбомнарда шәһәр һәм авыл урамнары, агач йортлар, өйләрнең тышкы һәм эчке бизәлеш төрләре урыннарга барып тикшеренүләр нигезендә тупланган, тасвирланган һәм җентекләп сурәтләнгән. Бу материаллар Казанның агач торак йортларының, Татарстанның кече шәһәрләре һәм авылларының тарихи йөзен торгызу, шулай ук башкалабызның заманча агач төзелеш архитектурасын үстерү өчен кыйммәтле тәҗрибә буларак кирәк. Агач эшкәртүнең заманча технологияләре зур җәмәгать биналары, күпфатирлы йортлар төзергә мөмкинлек бирә. Бүген агач төзелеш шәһәрләрне экологик яктан тотрыклы үстерү потенциалы буларак карала. Яңа агач төзелеш архитектурасының тарихи мирас белән бәйләнешне саклавы да мөһим. Тарихи мираска караган күп нәрсәне актуальләштерергә һәм киләчәккә күчереп алырга мөмкин.

Татарстанда 2023 ел Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Авторның Казан, Әтнә, Биектау, Мөслим, Актаныш, Балык Бистәсе, Саба районнарының агач төзелеш архитектурасы мирасы буенча 800дән артык аквареле тупланган җиде томлы архитектура-сәнгать альбомнары сериясе Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерүгә, баетуга зур өлеш кертә. Равил Сәйяр улы Айдаров, һичшиксез, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек.

Сергей МИХАЙЛОВ, КДАТУ профессоры,
сәнгать белеме докторы,
Россия Дизайнерлар берлеге вице-президенты


Әтнә авылындагы агач мәчет.

ВАДИМ ВАЛЕНТИНОВИЧ КЕШНЕР
(22.03.1937 – 14.04.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы халык артисты Вадим Валентинович Кешнер 14 апрельдә 87 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Вадим Кешнер 1937 елның 22 мартында Казан шәһәрендә туган. 1957 елда Казан дәүләт университетының филология факультетына укырга кергән. 1958–1961 елларда В.Качалов исемендәге Казан Зур драма театры каршындагы театр студиясендә белем алган.

1961 елда ул В.Качалов исемендәге Казан Зур драма театры артистына әйләнгән. Вадим Кешнер театрда ярты гасыр дәвамында хезмәт итү чорында дөнья һәм рус классикасы, заманча драматургия буенча 120дән артыграк роль башкарган. Аның кабатланмас образлары арасында – «Обыкновенная история» спектаклендәге Александр Адуев, Пушкин («Всего 13 месяцев»), Уилл («Быть или не быть»), Максимов («Коллеги»), Глумов («На всякого мудреца довольно простоты»), Атташе («Господин Пунтила и слуга его Матти»), Персиков («Роковые яйца»), Жеронт («Плутни Скапена»), Земляника («Ревизор»), Сосед («Горько!..»), Капитан Шотовер («Дом, где разбиваются сердца»), Жюльен Феррон («Тайна дома Вернье), Дворецкий («Визит дамы») һ.б.

Вадим Кешнер театрга намуслы хезмәт иткән зур артист иде. Аның һәрбер роле театр тормышында әһәмиятле вакыйгага әйләнде. Ул шигырь һәм иҗат кичәләрендә, тамашачылар белән очрашуларда даими катнашты, телевидениедә чыгышлар ясады.

Вадим Валентинович остазлыкка зур игътибар биреп килде: ул яшь актерлар буыны өчен педагог, тәрбияче булды. Казан театр училищесында педагогик эшчәнлек алып барды.

Вадим Кешнерның югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы күпсанлы бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Фидакарь хезмәт өчен» һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте бар. Россия гуманитар фәннәр академиясенең мактаулы академигы, «Тантана» республика премиясенең «Намус һәм вөҗдан өчен» номинациясе лауреаты булды.

Республиканың театр сәнгатен үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән талантлы артист һәм педагогның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә.Ә. СӘФӘРОВ, И.Х. ӘЮПОВА, И.Р. МЕТШИН,
А.Я. СЛАВУТСКИЙ, Ф.Р. БИКЧӘНТӘЕВ

Диплом о среднем профессиональном образовании СТ № 181657, выданный ГАОУ «Казанский медицинский колледж» в 1992 г., рег. номер 5603 на имя Юнусовой Рамзии Юсуповны, в связи с утерей считать недействительным.


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

КОТЛЫЙБЫЗ!

Журналистлык эшчәнлеген 1972 елда «Социалистик Татарстан» газетасында башлаган мөхтәрәм шәхес Ислам Галиәхмәт улы ӘХМӘТҖАНОВ бу көннәрдә 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Буа районының Норлат авылында туып-үскән, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә белем алган җор күңелле, үткен телле егетнең язмаларын газета укучылар шундук үз итә. Ул тирән фикерле, вакыт-вакыт юмор хисе белән дә сугарылган мәкаләләре белән абруй яулый. Тора-бара «Татарстан яшьләре» газетасына редактор вазыйфасына билгеләнә. Ленинград Югары партия мәктәбендә белем камилләштерү дә насыйп була. Татарстан матбугат министры, «Идел-Пресс» нәшриятында генераль директор, Татарстан Дәүләт Советы депутаты буларак бөтен тырышлыгын, белемен биреп, тәҗрибәсенә таянып, эш кешесенә олы ихтирам күрсәтеп хезмәт итә. Тарих фәннәре кандидаты Ислам Галиәхмәт улы яшь буынны тәрбияләүдә дә тырышлыгын кызганмый.

Ислам Галиәхмәт улының киләчәктә дә Рушания ханым белән озын-озак, берсенә терәк-таяныч булып, кызлары Диана гаиләсенең кадер-хөрмәтендә гомер итүләрен телибез.

«Ватаным Татарстан» газетасы коллективы

Авыл язмалары

Илдар Мөхәммәтҗанов

Их, бер яңгыр!

Авыл кешесенә бер генә язны да тыныч күңел белән каршыларга насыйп түгел бугай. Арада, Тукаебыз язганча, җиле дә вакытында исеп, яңгыры да вакытында яуган еллар бик сирәк була. Үткән ел бу вакытларда үзе явымлы, үзе салкын булып (әле май ае тулысынча диярлек), язгы кыр эшләре соңга да калды, мәшәкатьле дә булды. Хуҗалыклар гына түгел, гади кешеләр дә бәрәңге җирләрен эшкәртә, утырта алмый тилмерде. Гомер булмаганны, тип-тигез урындагы, язгы сулар да кермәгән, сазлыклы да булмаган өй яннарындагы бакчаларны да май азагында гына эшкәртә, бәрәңге утырта алдык.

Быел менә киресенчә: көннәр дә коры, кояшлы да кебек. Карап торышка, язы да иртә килде. Әмма бакчага чыгып, җир эшләренә тотына торган түгел. Дөрес, күмәк хуҗалыклар җир җитешкәнне, көннәр җылынганны көтеп тормады. Җир кардан арчылган икән, башкарасы эшләре чиратка тезелә. Башка елны кар бетәр-бетмәстә, иртән җир каткан чакта уҗымнарны, күпьеллык үлән басуларын ашласалар, быел кар кинәт бетте. Ул көннәрдә иртә-кичен суытмады да, шуңа күрә ашлау өчен дә басуларның байтак кипшергәнен көтәргә туры килде. Быел бөтенләй башка режимда эшләделәр. Әмма бер тотынгач, инде тукландыру эшләрен тәмамлап, җир эшкәртү, чәчүгә дә керештеләр. Ел ничек килсә дә, аларга чарасын табасы, дым югалып беткәнче анысын да, монысын да эшләп өлгерергә кирәк.

Ә дым сәгатьләп-минутлап юкка чыга. Аңа карап, әле җирдән пар күтәрелмәде, иртә-кич салкын булгангадыр, аның өсте генә ката, аскы өлеше өлгерми. Кар беткәнгә айдан артык вакыт үтте, шуннан бирле бер тамчы кар, яңгыр да яумады. Иҗ гаҗәбе: бер ай элек кардан арчылган урыннар да бүгенгәчә шул килеш, шәп-шәрә булып утыра. Өлкәнрәкләрнең дә мондый хәлне күргәне булмаган, аптырата да, куркыта да диләр. «Их, бер яңгыр!» – ди бүген сала кешесе. Үләннәр дә күтәрелеп китәр, җир дә «пешәр», табигать тә хәл алыр иде, шул бер җылы яңгырны гына көтәдер – бар дөнья яшәрер иде.

Ел елга охшамый дисәк тә, гадәттә, мондый хәвефле коры, җилле көннәр апрель азагында – май башында санаулы гына була иде. Быел озаккарак китте. Шул көчле җилләр җирнең җелеген суыра да инде. Табигатькә чыксаң, шакката торган: әйтерсең, кырык градуслы эсселәр ай буе торган, үткән елдан калган үләннәр шул дәрәҗәдә корыган, хәтта бер-берсе белән ышкылып та кабынып китәр кебек. Эссе җәйге көннәрдә киптергән печән дә әле ул дәрәҗәдә коры булмый… Язгы якта гадәттә үләннәрдә сут була иде, төбеннән чыгып килә торган үсентеләрдәге дым хисабынамы, корыган үләннәрне кайчакта сындырып та алып булмый иде, быел барысы да коры шырпы кебек шытырдап сына…

Табигать куркыныч дәрәҗәдә корыган. Шуңа да социаль челтәрләргә керергә, яңалыкларга күз салырга да куркыныч: әле анда, әле монда янгыннар, бик күбесе коры үләнгә ут кабудан яки кабызудан башланган… Коры, җилле көннәрдә, мондый вазгыятьтә кечкенә генә саксызлык та зур афәтләр чыгарырга сәләтле шул.

Бүген ашланган күпьеллык үлән җирләре дә, көзге чәчүлекләр, яңа чәчелгәне, эшкәртелгән-эшкәртелмәгән җирләр дә, үлән шыта алмый тилмергән тау битләре-яланнар да яңгыр көтә. Аларга кушылып без дә: «Их, бер яңгыр!» – дибез. Фаразлары чынга ашса, бу атнага синоптиклар яңгырлар вәгъдә итә дә… Хәерле, шифалы яңгырлар булсын иде инде!

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАМАК ТҮГЕЛ, КҮҢЕЛ ЙӨРТСЕН

Рамазан – 2023

Быелгы Республика ифтарыннан күпләр әнә шундый уйлар белән кайткандыр, мөгаен. Юк, мөселманнар көтеп алган әлеге мөһим вакыйганы оештыручылар бакчасына атылган таш түгел бу. Бирегә кунакка килгән кайбер кардәшләребезнең кыланмышыннан соң күңелгә кереп оялаган каршылыклы хисләр…

tatarstan.ru

- **XI Республика ифтарында 11 меңнән артык кеше катнашты. Алтышар кешегә исәпләнгән 1860 өстәлгә табын корылган иде.**
- **Бер кешегә уртача 800 сумлык ризык әзерләнде.**
- **Ифтарда катнашучылар пылау, кипкән җиләк-җимеш, камыр ризыклары, тәм-томнар, су, төрле җиләк-җимешләр белән авыз ачты. Оештыручылар киләсе елга төп ризык саналган пылауны башка ризыкка алыштырмакчы.**
- **Республика ифтарына билетлар киләсе елга да электрон рәвештә булыр, дип фаразлана.**

«Казан Экспо» бусагасын атлап керүгә үк, бөтенләй үзгә мохиткә килеп эләгәсең. Үзебезчә – мөселманча киенгән кардәшләрдән зал гөжләп тора. Араларында төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, чит төбәкләрдән кунаклар, мохтаҗлар һәм аз керемлеләр – барысы да бар. Моңа кадәр үткәрелгән кайбер кәттә ифтарлардан аермалы буларак, халыкны ниндидер катлауларга аеру, VIP дип масаюлар юк биредә.

Яшермим: ифтарда быел 11 меңнән артык кеше катнашачагын белгәч, бу кадәр халыкны ничек көйләп, чараны ничек оештырып чыгарлар икән, дигән шик бар иде. Куркынычсызлык мәсьәләсе дә борчымады түгел. Әмма биредә һәр нәрсә барлык нечкәлекләренә кадәр уйланган. Ишек төбендә каршы алган волонтер кызлар билетың бармы-юкмы икәнлекне барласа, эчкә үткәннән соң исә сак хезмәткәрләре чарага килгән һәркемне җентекләп тикшереп кертте.

Программада табын янында ифтар кылу вакыты ярты сәгатькә соңрак дип күрсәтелгән иде. Уразалы кеше намаз укылган залда ук авыз ачарга тиеш була, димәк. Оештыручылар анысын да исәптә тоткан. Керә-керешкә һәркемгә кечерәк кенә бер шешә су бирәләр. Шунда ук намаз уку бүлмәсенә кергәндә тышкы аяк киемен салып кую өчен пакет та тоттырып җибәрәләр. Хәзер кая барыйм икән, дип тә баш ватасы юк. Бар нәрсә күрсәткечләрдә, элмә такталарда тәгаен аңлатылган.

Елдагыча республика ифтарында хәләл кибет оештырылган иде. Анда хәләл тәм-томнан башлап, бизәнү әйберләре, милли кием-салым һәм башка әйберләр урын алган. Фойеның бу өлешенә зур павильонда бәйрәм чарасы башланып киткәч тә тузан төшмәде. Әлки районыннан килгән Мәдинә Абзалова кызларына ифтар күчтәнәче итеп ике яулык алды. Республика ифтарында катнашу өчен, Кадыш бистәсендә яшәүче туганнарына кичтән үк килеп кунган ул.

– Мондый милли бизәкле яулыкларны телевизордан рекламада гел күрсәтәләр. Казанга барсам, алырмын дип кызыккан идем. Монда да саталар икән. Ел саен шушы зур ифтарга барасым килеп кала иде. Андый җиргә җыена башласаң, гел бер сәбәбе чыгып тора бит. Әле бакча дисең, әле нәрсә. Быел бернәрсәгә кармыйча, барам, дидем. Үлгәнче бер күреп каласы иттем, эш качмый ул, – ди Мәдинә апа.

Быелгы ифтарга бай мәдәни программа да әзерләүләрен хәбәр иткән идек инде. Тантаналы ачылыштан соң ифтарга җыелучылар игътибарына «Дәрвиш» моноспектакле күрсәтелде. Буа дәүләт драма театры җитәкчесе Раил Садриев бер сәгать чамасы берүзе сәхнә тотты. Тумышы белән шушы районнан булган данлыклы имам Нургали Хәсәновка багышланган әлеге спектакльдә күңелгә тигән, уйландыра торган урыннар шактый, фәлсәфәсе тирән иде. Әмма моны биредә утырган һәркемнең дә аңлавына гына шикләндем. Ник дигәндә, 11 мең кешене сыйдырган зур залда сәхнәдән килгән тавыш мизгел эчендә югалды. Ир-атлардан соң, залның икенче өлешендә утырган хатын-кызларга бөтенләй аһәң кебек кенә ишетелде ул. Беренче коймактагы бу төерләр киләсе елга исәпкә алыныр дип өметләнәсе килә.

Сәгать телләре 18 сәгать 49 минутны күрсәтә… Шушы залга җыелган бар мөселман, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга ияреп, җәмәгать белән ахшам намазы укыды. Алгы рәтләрдә улы белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та бар иде. Мәртәбәле кунаклар арасында Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Илчелегенең Россиядәге беренче сәркатибе Мөхәммәд Рәшид Әлмансури, Катарның Россиядәге илчесе урынбасары Абдулла Юсеф Әл Сааи, Төркия, Иран, Төрекмәнстан, Казахстан, Үзбәкстанның Казандагы генераль консуллары да шәйләнде.

Ахшам намазы укыганда, залда күңелгә шулкадәр рәхәт мохит урнашты. Һәркем бу мизгелдә, бар дөнья мәшәкатьләрен онытып, Аллаһка якынаерга, теләкләрен теләп калырга ашыкты. Дөрес, арабызда башка юнәлешкә ашыгучылар да шактый булды. Залда моноспектакль караучыларның бер өлеше, җәмәгать белән укылачак намаз башланганчы, залдан чыгып таю ягын карады. Чыгуга, туп-туры авыз ачу өчен өстәлләр әзерләнгән павильонга китте алар. Республика ифтарында күңелгә тигән тагын бер нәрсә әнә шул булды. Юкса һәркемнең кулында билеты бар, табындагы ризыклар да һәркемгә җитәрлек итеп әзерләнгән.

Әмма гаҗәпләнерлек хәлләр алдарак көткән икән. Намаз укучылар ифтар узачак залга кергәндә, халыкның бер өлеше табыннар янында утыра иде инде. Ул гына да түгел, кайберәүләр инде янындагы буш урыннардагы ризыкларны да, пакетка тутырып, өенә алып кайтырга әзерләп куйган. Башына түбәтәй кигән 60 яшьләр тирәсендәге абзыйның бу гамәлен күреп шаккаттым. Кисәтү ясауга да исе китмәде аның. Ишетмәмешкә салышып, шундук чукракка әйләнде. Соңрак социаль челтәрләрдә тагын бер ир-атның яңа корылган табынны бушатып йөргән видеосы таралды. Янындагы ак яулык япкан хатын-кыз исә табынның икенче ягындагы кеше әле кагылып та карамаган ризык тулы тәлинкәләрне пакетка тутыра. Берсе дә мохтаҗ да, гарип-гораба да түгел! Барысы да ыспай киенгән! Бөтен нәрсәләре бар! Оятлары, намуслары гына юк!

«Казан Экспо»дагы мохитне күреп, күңелләр нечкәреп, мөселман булуым белән тагын бер кат горурланып куйган идем. Көн азагындагы менә шушы күренештән соң бу хисләрне алыштырдылар да куйдылармыни! Ә бит чараны шундый дәрәҗәдә оештыру өчен күпме көч түгелгән! Шушы 11 меңнән артык кешенең барысын да кабул итү, урнаштыру, ашату-эчертү бар нечкәлекләренә кадәр уйланылган!

Шушы табыннарны кору өчен җаваплы 600ләп волонтер да иртә таңнан бирле аяк өстендә бит! Әле күбесе үзләре дә уразада. Ниндидер дәрәҗә, файда өчен дә түгел, күңел кушканга алынган алар бу эшкә. Араларында, республика ифтарын оештырырга үз өлешемне кертәм дип, Мәскәү, Уфа, Төмән, Йошкар-Оладан ук килүчеләр дә бар. Әлеге чарада бишенче ел рәттән волонтер булып катнашучы Хәйрия Хәлитова, туган көн дип тормаган, ел да башкарган саваплы гамәленә алынган әнә. «Туган көн дип кенә бу мөһим чарадан кала алмадым. Күңелем шулай куша. Булышырга теләдем. Бу зур бәйрәмне көтеп алдым», – ди ул.

Республика ифтары әнә шундый күңел көтеп алган зур бәйрәм, мөселманнарны бергә җыя, берләштерә, уйландыра, күңелләрне пакьләндерә торган чара булып калсын, үз йөзен югалтмасын иде! Мөселманнар да бирегә тамак өчен түгел, күңел хакына йөрсен!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«БЕТТЕ-КИТТЕ»ДӘН НИ КАЛДЫ?

Премьерадан соң уйлану

«Яратам! Бетте-китте!» Тинчурин театрындагы чираттагы премьераның атамасы әнә шундый, бик гади. Куелышы да, эчтәлеге дә исеменә тәңгәл. Саллы-саллы премьералардан соң бу кадәр җиңеләю хәтта беркадәр сәер дә булды.

tinchurinteatr.ru

Шулай итеп, Актанышта яшәп иҗат итүче Ләйсән Әминованың пьесасын Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисов сәхнәләштерде. Әйткәнебезчә, спектакль бик гади, авыл тормышында булган хәл-вакыйгаларга нигезләнгән. Вакыйгалар ике генә йортлы Җиләкле алан авылында бара. Тыныч, салмак кына тормыш кичергән өч картның дөньясына, мәхәббәтнең ни икәнен дә аңламаган Гөлия (Лилия Камалиева) белән Роман (Эдуард Никитин) килеп керә. Яшьләрнең яшьлек юләрлекләре, үпкәләшүләре, ярсулары Фаил (Татарстанның атказанган артисты Ренат Шәмсетдинов) картның күңеленә тия. Шук бабай өзелергә торган сөю җебен ялгар өчен мәхәббәт сценарие «яза». Әмма язмыш Фаил бабай планыннан да кызыграк булып чыга. Биредәге һәрбер геройның тормышын бөтереп алып, үткән хатирәләргә, яшьлектәге хаталарга, хыянәтләргә, хөрмәткә һәм иң мөһиме – мәхәббәткә алып кереп китә.

«Тормышны яратучы, көр күңелле, бернинди кайгыга бирешми торган, һәр нәрсәдән позитив эзләүче һәм башкаларны да артыннан ияртеп баручы рәхәт кеше». Зөфәр Харисов төп геройның легендар Әлмәндәр картка охшаш булуын әйтте:

– Бер укуда пьеса да, төп герое да роль буларак күңелемә ошады. Мин аны директорга тәкъдим иттем. Бер-ике атнадан режиссерыбыз Туфан Имаметдинов, мине чакыртып, әлеге пьесаны куябыз, диде. Риза булдым, чөнки бу пьесада – мин яраткан авыл халкының нәкъ үзе. Теле шулкадәр матур, аңлаешлы. Мин моңа бик рәхәтләнеп алындым, – дип сөйләгән иде ул спектакльгә багышланган матбугат очрашуында.

Бетеп баручы авыл, гореф-гадәт, йола күренешләре, сандыкларда гына саклана торган халкыбыз тарихы. Спектакльнең төп мотивлары әнә шул. Хикмәте дә гап-гади. Хәзер сәбәбен эзләми, артык катлауландырмый, чын күңелдән яратырга кирәк. Мәхәббәтне сандыкка салырга ярамый.

Комедия булгач, спектакль дәвамында көләрлек урыннар байтак иде. Фаил карт ролен Ренат Шәмсетдинов үзенә генә хас юмор хисе белән башкарды. Төп геройның хатыны исә – тыйнак, сабыр, иренә дус, мәрхәмәтле булып яши торган татар хатын-кызы. Мәйсәрә ролен Татарстанның атказанган артисты Лилия Мәхмүтова башкарды. Тормышта да ирле-хатынлы булгангамы, бик табигый иде, сәхнәдә бер-берсен тулыландырып тордылар.

Спектакльдә музыкаль бизәлеш тә аерым игътибарга лаек. Ретро җырлар вакыйгаларга мәгънәви төсмер өстәде, һәр геройның образын ачарга ярдәм итте, аларның яшерен хисләрен чагылдырды. Бер мичкә балга бер кашык дегет дигәндәй, фонограммага җырлау гына матур башлангычның нәтиҗәсен боза язды.

– Кечкенәдән дәү әни, бабайлар белән үстем. Мин үзем шуның белән бәхетле. Алар өйрәткән матур җырлар истә калган. Бу спектакльгә бабам җырлаган җырны кертергә булдык. Аны заманында әни дә җырлый иде, – диде Лилия Мәхмүтова.

Гади тамашачыга ошар бу спектакль. Тормышчан булуы, артистларның уйнавы, яңгыраган җырлары белән җәлеп итәр. Тик күңелгә уелып кала алырмы ул? Спектакль финалында ни буласын болай гына әйтеп булмый, көтелмәгән хәлләр күп була дигәннәр иде. Анысы шулай. Тик аны «бөтен ялгызларны кавыштырып куйыйк та, шуның белән шул», – дип кенә төгәлләгәннәр кебек фикер туды. Нидер җитми калды.

Ләйсән САФИНА

Фикер

Айдар ШӘЙХИН,
Татар китабы йорты директоры:
– Бу спектакль Кәрим Тинчурин театрының классик репертуарына охшаш. Киң күләмле, гомуми тамашачыга рәхәтләнеп ял итәр өчен менә дигән спектакль. Аның үзенә күрә бер фәлсәфәсе, автор тарафыннан салынган матур мәгънәсе бар. Ләкин куелышның билгеле бер кытыршы урыннары да бар. Спектакльнең финалы зәгыйфьрәк чыккан. Спектакльдәге финал пьеса авторының текстында, аның күзаллавында булган финал түгел. Анда үзгәрешләр кертелгән дип беләм. Бәлки, бу куелыш өчен ул үзгәрешләр дөресрәктер. Әмма финалдан каршылыклы тәэсирләр кала. Ул күңелле, ләкин аны, бәлки, югарырак дәрәҗәдә дә оештырып булгандыр.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 255

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+